
Руслан Каюм улы vз хужалыгы очен урынны бик унышлы сайлаган. Ферма авылдан, урманнан һәм елгадан ерак тvгел урнашкан: су да, котv урыны да. Агрофирма янәшәсендәге кырлардан, чәчvлекләрне агулауга юл куймас очен, электрон котvлек белән әйләндереп алынган. Эшен һәм фермер хужалыгын ныгытуны кыенлаштыра торган катлаулы хәлләргә карамастан, Руслан Каюм улы Мещеров боларнын барысы да вакытлыча һәм козен хәл яхшы якка vзгәрер дип ометләнә. Аерым алганда, кvпләп сатучылар белән сарык ите белән тәэмин итv турында килешеп булачак. Чонки ул тәкъдим итә торган продукция сыйфатлы.

Коронавирус пандемиясе аркасында килеп туган катлаулы хәл крестьян-фермер хужалыкларында да чагылыш таба. Бигрәк тә сvз аякка басарга олгермәгән, Ләмберә районы Пензятка авылыннан Руслан Каюм улы Мещеров хужалыгында булган кебек, яшьләр турында барса. Руслан «Куйбышев» токымына басым ясап, сарыкчылык белән шогыльләнә. “Мәрмәр” сарык ите житеш-терә.
- Әлегә барысын да бурычка алырга туры килә, - ди Руслан Каюм улы. - Козгә барыбер сарык ите сатып булыр дип ометләнәм. Яркаларны vрчетергә калдырырбыз. Табыш китерсен очен бер меннән дә ким булмаган сарыгын булырга тиеш. Бездә әлегә ике йоздән генә артык. “Куйбышев” токымлысын vрчетv кыен булмаса да, проблемалар кvп туа. Кирәкле техника сатып алу момкинлеге юк, барысын да арендаларга туры килә, тюклар белән тоялгән машинага кvрсәтеп. Азык та кыйммәтле: сарыкларга ашлык та кирәк, ә ул арзан тvгел. Итнен килограммын (тере килеш) уртача 150 сумнан сатам. Сугым цехы юк, шуна кvрә аны болай гына сатарга туры килә. Дорес, Мәскәvдә ниндидер бәйләнешләр бар, бәлки, кvпләп сатучылар белән килешеп булыр. Ин моһиме - барлык чикләvләрне һәм тыюларны тизрәк тошерv. Һәм, әлбәттә, беренче ике – оч елда гына да яна эш башлаучы фермерлар очен салымнар буенча ташлама булсын иде. Ә бит елына йоз мен сум чамасы салымнарга китә, хәзер табыш юк диярлек. Ә бит әле ярдәмчеләргә хезмәт хакын тvләргә кирәк, берvзен генә фермада эшләп булмый. Менә шулай килеп чыга да! Шулай да, әйткәнемчә, ин моһиме - бу вакытлар тизрәк vтсен иде. Миндә сарыкчылык бе-лән шогыльләнv теләге бар, тәжрибәм дә бар, мине дә vз вакытында бу эшкә әти бик тә яхшы ойрәтте.

**Н.ХӘЛИЛ**